БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 12 2023 ел № 334

**Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында**

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) өстәмә ярдәм итү максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәттә катнашу турында контракт төзегән гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция зонасына командировкаланган Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, шулай ук «Россия Федерациясендә хәрби мобилизация турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар балалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 112 номерлы «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәттә катнашу турында контракт төзегән гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция зонасына командировкаланган Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар балалары (алга таба - гаиләләр) өчен түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

1.1. Балтач муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә баланы караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү.

1.2. Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә 1-11 сыйныф укучыларын ике тапкыр бушлай кайнар туклану белән тәэмин итү;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары карамагындагы мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләрдә һәм өстәмә белем бирү секцияләрендә дәресләр өчен түләүдән азат итү;

1.4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә музейларга бушлай бару;

1.5. Түләүсез спорт - тренажер залы һәм спорт заллары булган «Дулкын» ябык йөзү бассейны;

1.6. Көндезге мәктәп яны лагерьларында ата-аналар взносын түләүдән азат итү.

1.7. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты буйсынуындагы учреждениеләр уздыра торган мәдәният - ял вакытларын уздыру, мәдәни - тамаша кылу һәм сәнгать өлкәсендәге башка чараларга түләүсез керү.

1.7.1. Әлеге карарның 1.7 пунктында каралган социаль ярдәм чарасына хокукны алу өчен урыннарны күчереп утырту каралган чараларга билетларны алдан ук броньларга киңәш ителә, бу карарның 1.7 пунктында каралган чарага кадәр 5 календарь көннән дә соңга калмыйча учреждение кассасына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Буш урыннар булганда балаларга чарага билетлар биреләчәк, чарага буш урыннар булмаган очракта, чаралар исемлегендә китерелгән башка чараларга килергә тәкъдим ителә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чаралары гражданинның "Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында" 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Кораллы көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорына каралган.

3. Әлеге карарның 1.1 пункты 2023 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә тәэсир итә.

4. Карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

-2022 елның 28 октябрендәге 305 номерлы "Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәмнең өстәмә чаралары турында" карары;

- 2022 елның 24 ноябрендәге 334 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәмнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 28 октябрендәге 305 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм

Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов